**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Өҗем авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

«20» ноябрь 2019 ел. № 109

**Өҗем авыл җирлеге Советының 2009 елның 6 августындагы 14 номерлы «Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эшләүне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турында Нигезләмә" карарына үзгәрешләр кертү турында**

Прокурорның 2019 елнын 30 сентябрендәге 02.08.02-2019 номерлы протестына таянып, 1999 елнын 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турындагы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакындагы» Федераль закон нигезендә һәм Әтнә муниципаль районының «Өҗем авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советының 2009 елның 6 августындагы 14 номерлы «Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эшләүне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы Нигезләмәне» раслаган карарына бирелгән Әтнә районы прокуратурасының 2019 елныц 30 сентябрендәге 02.08.02-19 номерлы протесты белән килешергә.

2. Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы Нигезләмә нормаларын җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эш оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару тәртибен регламентлаучы гамәлдәге федераль законнарга туры китерергә.

3. Өҗем авыл җирлеге Советының 2009 елның 6 августындагы 14 номерлы карары белән расланган Нигезләмә пунктларына 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

4. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының интернет челтәрендә atnya@tatar.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Өҗем авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Өҗем авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлеге башлыгы: Вәлиев А.Т.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 нче
ноябрендәге 109 номерлы карарына 1 нче кушымта

Өҗем авыл җирлеге Советының 2009 елның 6 августындагы 14 номерлы карары белән расланган Нигезләмә пунктларына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) **2 статьяның 2.5 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:** "индивидуаль (персонификацияләнгән ) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында теркәлүне раслаучы документ;»

Өҗем авыл җирлеге башлыгы                                        Вәлиев А.Т.